**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Биккол авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«01» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге Биккол авылы торак пункты гражданнары җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Элек расланган гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертергә:
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 ның 10 октябрендәге 1 номерлы карары
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында гражданнар җыенының 2023 ның 10 октябрендәге 2 номерлы карары,
аны түбәндәге редакциядә раслап:

«2024 елда үзара салым кертүгә Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы көрәштә кулланылучы инвентарь сатып алу; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Биккол авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Биккол торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кыш көне карап тоту)»

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х.Әхмәтшина

Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Әхмәтшина